**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сәпәй авылы № 63 25 сентябрь 2017 ел.

Сәпәй авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча,җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Сәпәй авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Сәпәй авылы башкарма комитетының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Сәпәй авыл җирлеге Советының 11 сенбябрь 2017 елда чыккан 61 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сәпәй авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Сәпәй авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2017 елда 300 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме? Үзарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   - Җирле әһәмияттәге автомобиль һәм җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге юлларны карау, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы белән тәэмин итү (Сәпәй , Мачаклы-Баш авылы урамнарындагы юлларны ремонтлау (щебенка белән каплау);
   - Сәпәй авылы Мәктәп урамында урнашкан зиратны коймалау;
   - авыл урамнарын кардан арындыру чаралары;
   - җирлектэге чүп уләннәрен чабу.

   " РИЗА" "КАРШЫ"

1. Әлеге карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә түбәндәге веб – адрес буенча http://aznakyevo.tatarstan.ru урнаштырыла.
2. Әлеге карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис: Ф.Г.Галиева